| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.06.2019 Казан ш. № 6-24/тп

Тоташтырыла торган җылылык басымының куәт бирәмлегенә хисаплаганда «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «Җылылык белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик ялгау), җылылык белән тәэмин итү өлкәсендәге хезмәтләрдән дискриминацион булмаган файдалану мөмкинлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм көчләрен югалткан дип тану турында» 2018 елның 5 июлендәге 787 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) хисаплап чыгару буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, мөрәҗәгать итүченең тоташтырыла торган җылылык басымы сәгатенә 0,1 Гкал артык һәм сәгатенә 1,5 Гкал артмаучы объектын «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) очрагында тоташтырыла торган җылылык басымының куәт бирәмлеге исәбеннән түләү билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 14.06.2019
№ 6-24/тп карарына кушымта

# Мөрәҗәгать итүченең тоташтырыла торган җылылык басымы сәгатенә 0,1 Гкал артык һәм сәгатенә 1,5 Гкал артмаучы объектын «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) очрагында тоташтырыла торган җылылык басымының куәт берәмлеге исәбеннән түләү

мең сум/Гкал/сәг (НДС исәпкә алмыйча)

| Номеры | Аталышы | Билгесе |
|---|---|---|
| 1 | Мөрәҗәгать итүчеләрнең объектларын тоташтыру чараларын үткәрүгә чыгымнар ($П_1$) | 10,006 |
| 2 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан мөрәҗәгать итүчеләрнең тоташтырыла торган җылылык басымы 0,1 Гкал/сәг артык һәм 1,5 Гкал/сәг артмаучы объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык челтәрләре ясауга (үзгәртеп коруга) (җылылык пунктлары төзүдән (үзгәртеп корудан) тыш) чыгымнар, ($П_{2.1}$), шул исәптән: | |
| 2.1 | Җир өстеннән (җир өслегеннән) салу | |
| 2.1.1 | 50-250 мм | - |
| 2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | – |
| 2.2 | Җир астыннан салу, шул исәптән: | |
| 2.2.1 | канал белән салу | |
| 2.2.1.1 | 50-250 мм | 1 967,730 |
| 2.2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2.2 | каналсыз итеп салу | |
| 2.2.2.1 | 50-250 мм | 1 876,060 |
| 2.2.2.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 3 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан мөрәҗәгать итүчеләрнең тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше 0,1 Гкал/сәг артык һәм 1,5 Гкал/сәг артмаучы объектларын | - |

| | | |
|---|---|---|
| | тоташтыру нокталарына кадәр җылылык пунктлары төзүгә (үзгәртеп коруга) чыгымнар (П $_{2.2}$) | |
| 4 | Табышка салым | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге